| | |
|---|---|
| **ГЛАВА ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2019 ел Федоровский ав. № 2

2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлаулары уздыру турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «2020 елга һәм 2021-2022 елларга план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге бюджеты проекты турында» карар буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 13 ноябрендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында халыкка игълан ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советының «2020 елга һәм 2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге бюджеты проекты турында» карары буенча халык тыңлаулары уздырырга.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүматый стендларында һәм рәсми сайтында 2019 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә:

халык тыңлаулары уздыру вакыты- 30.11.2019 10.00 сәг;

уздыру срогы – 1 көн;

уздыру урыны – ТР, Кайбыч районы, Федоровский ав., Тутаев урамы.,41 й. (авыл мәдәният йорты бинасы);

халык тыңлауларында фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгыш ясап катнашуга заявкалар бирелергә мөмкин адрес: ТР, Кайбыч районы, Федоровский авылы, Тутаев урамы, 41 й.( эш көннәрендә - 8.00 - 17.00 сәг кадәр).

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына 2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм уздырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Федоровский авыл җирлеге
Башлыгы Ф.Ф.Зайнуллин